# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.8 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2009 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексының 3.8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2; Ватаным Татарстан, 2009, 1 август, 24 октябрь), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"3.8 статья. **Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозу**

Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозган өчен –

кисәтү ясала яисә гражданнарга – биш йөздән алып бер мең сумга кадәр, вазыйфаи затларга – биш меңнән алып ун мең сумга кадәр, юридик затларга егерме меңнән алып илле мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

Шушы гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган өчен –

гражданнарга – бер мең ярымнан алып ике мең сумга кадәр, вазыйфаи затларга – унбиш меңнән алып егерме мең сумга кадәр, юридик затларга алтмыш меңнән алып җитмеш мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш. Шәймиев

Казан, Кремль
2010 елның 12 гыйнвары
№ 4-ТРЗ